Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районының Колай авыл җирлеге

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Колай авыл җирлеге
Колай торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
**КАРАР**

7 декабрь, 2019 ел — № 5

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Колай авыл җирлегенең Колай торак пунктында 2019 елның 7 декабрендәге гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә авыл җирлегендә яшәүчеләр белән очрашу беркетмәсе нигезендә:

- җыенны уздыру өчен билгеләнгән территориядә яшәүче һәм халык җыенында катнашырга хокуклы гражданнар саны 804 (сигез йөз дүрт).
- халык җыены эшендә катнашкан гражданнар саны 412 (дүрт йөз унике).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**РИЗА**» өчен гомуми сан 407 (дүрт йөз җиде).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**КАРШЫ**» өчен гомуми сан 5 (биш).

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып түбәндәге карар кабул ителде:

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25 статьясындагы 6 өлеше нигезендә **гражданнар җыены мәсьәләсе буенча карарын**, түбәндәге мәсьәлә буенча «Сез 2020 елда Питрәч муниципаль Колай авыл җирлегенең Колай торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә, Чернобыль АЭСны бетерүдә катнашучылардан, 80 яшькә җиткән гражданнардан, 1 группа инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында һәм сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы студентлары һәм мәктәп укучыларыннан тыш үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә килешәсезме?:

- Колай авылы чиркәвенә кадәр юл ремонтлау;
- гомуми файдаланудагы урыннарны төзекләндерү»

**кабул ителгән дип санарга.**

2. Әлеге карарны «Вперёд» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Колай авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында да бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Колай авыл җирлеге башлыгы — Поповская — Н.В. Поповская